# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## "1941-1945 елларда Германияне җиңгән өчен" медале яисә "Японияне җиңгән өчен" медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы гражданнарының өстәмә ташламалары һәм җәмгыяви гарантияләре турында

"1941-1945 елларда Германияне җиңгән өчен" медале яисә "Японияне җиңгән өчен" медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы гражданнарының күп санлы мөрәҗәгатьләренең нигезле булуын исәпкә алып , Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

Бөек Ватан сугышында катнашучыларга бирелә торган җәмгыяви гарантияләр һәм ташламалар 1941-1945 елларда гамәли хәрби хезмәткә алынган һәм "1941-1945 елларда Германияне җиңгән өчен" медале яисә "Японияне җиңгән өчен" медале белән бүләкләнгән Татарстан Республикасы гражданнарына да кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 20 июле
№ 2192-XII